| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>НАДЕЖДИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>НАДЕЖДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 октябрь, 2020 ел Надеждино авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Репьевка авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2020 елның 29 октябрендә 10 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча гражданнар җыенын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Репьевка поселогы,Урман урамы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Репьевка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Надеждино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге башлыгы Е.В.Савельева